УДК 82-95

***Г.А. Хөснетдинова***

# ХАЛЫК МӘНФӘГАТЕН ЯКЛАП...

В данной публикации предлагаются неизвестные сегодняшнему читателю статьи Фатиха Амирхана (1886–1926), выдающегося татарского писателя и драматурга, эрудированного литературного критика, публициста, общественного деятеля, одного из основателей татарской периодической печати. Статьи «Бергәме, аерыммы?» («Вместе или врозь?») (1914, 17 августа, № 485) и «Мөфтилек мәсьәләсе вә аңар кандидатлар» («О муфтияте и о кандидатах») (1915, 26 июня, № 738) были напечатаны в 1914–1915 годах в газете «Кояш» за подписью «Фатих Амирхан».

Первая публикация написана в связи с созданием «Мусульманского комитета» для сбора пожертвований в пользу раненых и пострадавших в Первой мировой войне татарских солдат и ставит целью критику данной организации и ее инициаторов – Х. Максуди, Г. Салихи и С. Иманкулия.

В статье «О муфтияте и о кандидатах» Ф. Амирхан рассуждает о выборах и о кандидатах, претендующих на место умершего летом 1915 года муфтия Мухамедьяра Султанова (1836–1915). Автор выражает надежду, что правительство не станет игнорировать мнение простого народа и не назначит муфтием Баязитова или Капкаева.

Представленные статьи впервые печатаются на кириллице в текстологической обработке и с дополнениями.

**Ключевые слова:** Фатих Амирхан, татарская литература, газета «Кояш», публицистика.

This publication offers articles unknown to today’s readers by Fatih Amirkhan (1886–1926), an outstanding Tatar writer and playwright, an erudite literary critic, publicist, public figure and one of the founders of the Tatar periodical press. The articles “Bergame, aerymmy?” (“Together or apart?”) (1914, August 17, No. 485) and “Moftilek masalase va anar candidatlar” (“About the Muftiate and candidates”) (1915, June 26, No. 738) were published in 1914–1915 in the newspaper “Koyash” signed by “Fatih Amirkhan”. The first publication was written in connection with the creation of a “Muslim Committee” to collect donations for the benefit of wounded and injured Tatar soldiers in the First World War and aims to criticize this organization and its initiators – H. Maksudi, G. Salihi and S. Imankulia. In the article “On the Muftiate and the candidates”, F. Amirkhan discusses the elections and the candidates seeking the place of Mufti Mukhamedyar Sultanov (1836–1915), who died in the summer of 1915. The author expresses the hope that the government will not ignore the opinion of the common people and will not appoint Bayazitov or Kapkaev as mufti. The presented articles are being printed in Cyrillic for the first time in textual processing and with additions.

**Keywords:** Fatih Amirkhan, Tatar literature, newspaper “Koyash”, journalism.

Татар халкының иҗтимагый-сәяси аңы, әдәбияты һәм мәдәнияте тарихында мәңге җуелмас эз калдырган шәхесләр бар. Татар әдәбияты классигы, күренекле прозаик һәм драматург, киң эрудицияле тәнкыйтьче, ялкынлы публицист, җәмәгать эшлеклесе Фатих Әмирхан – шундый мәшһүрләрнең берсе. Аның иҗаты, барыннан да элек, үзенең күпкырлы һәм тирән булуы белән җәлеп итә, шуның белән бергә әдипнең татар матбугатын оештыруда һәм аны юлга салуда әйдәп баручылардан булуы да мәгълүм.

Журналистика өлкәсендәге тәүге адымнарын мәдрәсәдә кульязмада нәшер ителгән яшерен журналларда башлаган Ф. Әмирхан 1907 елда беренче татарча балалар журналы «Тәрбиятел-әтфаль»не оештыруда актив катнаша һәм анда сәркатиплек вазифасын үти. Әмма 1907 елның августында аны паралич суга, һәм ул калган гомерен коляскада үткәрергә мәҗбүр була. Көчле ихтыярлы, милләтенә хезмәт итү дәрте белән янган Фатихны бу бәхетсезлек сындыра алмый: ул актив эшчәлеген дәвам итә. 1907–1909 елларда «Әлислах» газетасы мөхәррире вазифасын башкара. 1912–1918 елларда, «Кояш» газетасында җаваплы сәркатип булып эшли, аның милләт мәнфәгатьләрен алга сөргән юнәлешен билгеләүдә төп рольләрнең берсен уйный. Ф. Әмирхан мәкаләләрендә татар дөньясындагы күренешләргә үзенең мөнәсәбәтен белдерә, үзен милләтпәрвәр фикер иясе һәм күренекле татар иҗтимагый-сәяси эшлеклеләренең берсе итеп таныта.

Журналыбызның бу санында Ф. Әмирханның бүгенге укучыга таныш булмаган «Бергәме, аерыммы?» (1914, 17 август, № 485) һәм «Мөфтилек мәсьәләсе вә аңар кандидатлар» (1915, 26 июнь, № 738) исемле ике мәкаләсе тәкъдим ителә. Алар 1914–1915 елларда «Кояш» газетасында «Фатих Әмирхан» имзасы белән басылганнар.

Ф. Әмирханның «Бергәме, аерыммы?» язмасы Һади Максуди, Мөхәммәдгариф Салихи һәм Садыйк Иманколыйлар инициативасы белән, яралылар файдасына иганә җыю өчен, «Мөселман комитеты» оештырылуы уңаеннан язылган. Максаты Беренче бөтендөнья сугышында (ягъни 1914 елда) яраланган яки сугышта зыян күргән татар солдатларына ярдәм итү булган бу комитет хакында мәгълүмат «Йолдыз» газетасының 14 август (1246 нчы) санында басыла. Ф. Әмирхан мөселманнар өчен мондый комитетның кирәксезлеген исбат итә, иганә җыю тиеш икән, бу эшне руслардан аерылмыйча, алар төзегән җәмгыятьләр аша эшләү дөресрәк булыр, ди. Бердәм булып эш иткәндә генә, бу ярдәмнең сугышта зыян күргәннәр өчен файдалырак, урынлырак булуына басым ясый.

«Мөфтилек мәсьәләсе вә аңар кандидатлар» дигән икенче мәкаләдә Ф. Әмирхан Диния нәзарәте мөфтие Мөхәммәдьяр Солтанов (1836–1915) урынына яңа мөфти сайлау мәсьәләсе турында яза. Мәгълүм булганча, әлеге уңайдан Казан, Уфа, Оренбург кебек татарлар күпләп яшәгән шәһәрләрнең зыялы һәм руханилары арасында

яңа куелачак дин башлыгының нинди булырга тиешлеге хакында бәхәсләр кыза, кандидатлар тәкъдим ителә. Вакытлы матбугатта да бу хакта күпсанлы мәкаләләр басыла, төрле фикерләр әйтелә, кандидатларның исемнәре санала. Җәмгыять хадиме булган Ф. Әмирхан үзенең мәкаләсендә хөкүмәт гади халык фикерен исәпкә алмый калмас, баюдан бүтән ихласы булмаган Капкаевны яисә исемен пычраткан Баязитовны мөфти итәргә базмас, дигән өмет белдерә.

Әмма патша хөкүмәте үзенчә эшли: 27 июльдә игълан ителгән фәрман белән мөфти итеп дин һәм җәмәгать эшлеклесе Сафа Баязитовны (1885–1937) билгели. Бу, үз чиратында, мөселман җәмәгатьчелегендә ризасызлык тудыра, матбугатта С. Баязитовка карата тәнкыйть мәкаләләре басыла.

Түбәндәге мәкаләләр гарәп графикасыннан гамәлдәге язуга күчерелеп, текстологик яктан эшкәртелеп һәм астөшермәләр белән тулыландырылып, укучыга беренче тапкыр тәкъдим ителә. Алар Институтның текстология бүлеге галимнәре тарафыннан әзерләнә торган Фатих Әмирханның алты томлы «Әсәрләр» академик басмасының 5 нче томында урын алачак.

## БЕРГӘМЕ, АЕРЫММЫ?

«Йолдыз» гәзитәсендә күрелгән бер игъланнан аңлашылуына күрә, Һади әфәнде Максуди, мулла Садыйк Иманколый һәм мулла Мөхәммәдгариф Салихи әфәнделәр сугышта мәҗрух төшкәннәр[1] файдасына иганә җыяр өчен бер комитет – «Мөселман комитеты» тәшкил иткәннәр икән.

Ватанымыз башына зур кайгы төшкән вакытта бөтен Русия гражданнары белән бергә бөтен Русия мөселманнары да ул кайгыны иңләтү юлларына керергә вә шул юлда кулларыннан килгән һичбер нәрсәне аямаска тиешләрдер. Ватан вә падишаһ өчен сугышка кереп мәҗрух булган кешеләр – иганәгә иң мохтаҗ кешеләрдер. Бу юлга бирелгән иганә – иң урынлы бирелгән иганәләрнең берсе вә әһәмиятлеседер. Монда һич шик вә шөбһә булырга мөмкин түгел.

Мадам ки[2], киң вә куәтле Русиядән без дә башкалар белән бергә файдаланамыз, аның куәтле вә нык булуы аркасында без дә рәхәт яшимез. Аның башына бәла килгән вакытларда шул бәла белән без дә көчемездән килгән дәрәҗәдә көрәшергә бурычлымыз. Бу эштә милләт вә дин аермалары юк, бу эш – бөтен русиялеләр өчен мөштәрәк[3] вә бертигез эш вә бертигез вазифадыр. Менә шул әсаслардан чыгып

[1] Мәҗрух төшкәннәр – яраланганнар.
[2] Мадам ки – чөнки.
[3] Мөштәрәк – уртак.

та, мин «Мөселман комитеты» тугрысында бер-ике сүз әйтеп китүне тиеш күрәм:

Бөтен русиялеләр өчен бертигез мөштәрәк булган бу эштә мөселманнарның руслардан аерым эш күрүләрен мин һичничек итеп аңлый алмыйм. Мадам ки бәла мөштәрәк, мадам ки аңар каршы тору – бөтен русиялеләр өчен мөштәрәк бер вазифа, без бу тугрыда руслар белән кулга-кул тотышып хәрәкәт итәргә, көчләрне аермыйча, бер ноктага җыеп хәрәкәт итәргә тиешләрмез:

– Ни өчен «Мөселман комитеты»?

– Ни өчен без мөштәрәк комитетларда, мөштәрәк мөәссәсәләрдә[1] хезмәт итмимез?

Мин бу сөальләргә[2] җавап таба алмыйм.

Тәэсис ителгән[3] әллә никадәр комитетлар бар; боларның башында ышанычлы вә тәҗрибәле кешеләр торалар, шулар булып торганда ни өчен мөселманнарга махсус комитетлар ясап, аны организовать итәргә көч тыгарга? Организовать итеп, аякка бастырылган мөәссәсәләрдә мөшарәкәт итеп[4] шунда эшләшкәндә бу көч мәҗрухлар өчен тагы да файдалырак, тагы да урынлырак төшәчәк бит! Ни өчен мондый гомуми эшләрдә руслардан аерым эш күрергә? Моның кирәген мин һичбер аңлый алмыйм.

«Мөселман комитеты» ясарга йөрүчеләр үзләренең игъланнарында болай диләр: «Әгәр дә үз комитетымыз булса, гайрәт вә сәдакатемез заһир улмак илә бәрабәр биргән суммамызның никадәр икәне дә мәгълүм булыр иде». Мин бу дәлилне рәдд итеп[5] торырлык дәрәҗәдә дә күрмим. Әгәр сәдакать[6] күрсәтү мәкъсуд[7] булса, бу эш руслар белән бергә эшләшкәндә бигрәк яхшы күренә.

Әгәр үземез биргән сумманың микъдарын белү мәкъсуд булса, моны да без үземез эшләшкән мөәссәсәләрнең хисабларыннан бик яхшы күрә аламыз. Әгәр без бик бай бер милләт булып та, бу эшкә әллә ничә миллионнар иганә итеп, рус ватандашларымызга да нәмунә[8] була алырлык, аларны да гыйбта[9] иттерә алырлык булсак иде – шул вакытта бәлки хосусый «Мөселман комитеты» тәэсис итеп торуның бер әһәмияте булыр иде. Ләкин хәл болай түгел бит! Тәэссефкә каршы[10], без андый бай бер милләт түгел, безнең иткән

---

[1] Мөәссәсәләр дә – оешмаларда.

[2] Сөальләргә – сорауларга.

[3] Тәэсис ителгән – төзелгән.

[4] Мөшарәкәт итеп – бергәләп.

[5] Рәдд итеп – кире кагып.

[6] Сәдакать – турылык, дуслык.

[7] Мәкъсуд – ниятләнгән.

[8] Нәмунә – үрнәк.

[9] Гыйбта – берәүдәге яхшы якларны күреп, үзеңдә дә шуны булдырырга теләү, кызыгу.

[10] Тәэссефкә каршы – кызганычка каршы.

иганәләремез дә шул үз көчемез нисбәтендәге, русча тәгъбир иткән «скромный» гына бер хисса[1] булачак – шулай булгач, мин бу тугрыда үз башымызга гына эш күрүнең һичбер кирәген тапмыйм, хәтта зарарлы бер эш дип уйлыйм. Безнең сугышка киткән кардәшләремез рус ватандашлары белән бер сафта үләләр, бер сафта торып мәҗрух төшәләр, шулай булгач, монда калган мөселманнар да бу тугрыда руслар белән кулга-кул тотышып, бер сафта вә бер көч белән эш күрергә тиешләрдер.

Безнең үз башымызга, үземез генә эшли торган милли эшләремез дә бик күп, гомуми ватан эшләрендә без һәрвакытта рус ватандашларымыз белән бергә, алар белән кулга-кул тотышып кына эшләргә тиешләрмез. Шулай булганда гына безнең ул эшләремез көтелгән файданы бирә алырлар. Мондый эшләрдә аерым йөрү файдасыз гына түгел, бәлки зарарлы булачактыр. Мондый эшләрдә көчләрне мөмкин кадәр бер җиргә җыю – хөкүмәтнең матлубыдыр[2]. Дахилия назыйренең министрлар мәҗлесенә керткән, 1912 ел 25 июнь законына тәтиммәсенең[3] әүвәлге маддәсендә «сугышка алынганнарның гаиләсен тәрбия тугрысында күрелә торган чараларның һәммәсен берләштерергә тырышуның» кирәклеге күрсәтеләдер. Шулай булгач, без бу тугрыда аерым эш күрүемезнең хөкүмәт өчен матлуб булуы да бик шөбһәле буладыр.

Менә шуларны хәтергә алып, мин русияле мөселманнарга бу тугрыда аерым эш күрмичә, руслар белән бергә хәрәкәт итүне, гомуми мөәссәсәләрдә бөтен көчләрен сарыф итеп хезмәт итүне тәүсыя итәр[4] идем. «Мөселман комитеты», «Татар комитеты» дигән шикелле аерым бер мөәссәсәләргә һич ихтыяҗ юк. Шәһәр, земство, «Красный крест» вә башкалар тарафыннан тәэсис ителгән әллә никадәр комитетлар бар. Мөселманнар шул комитетларда ихлас белән хезмәт итешсеннән, шул комитетлар аркылы иганә итсеннән – монда һәм сәдакать күренер һәм гомуми эшләргә өйрәнү табылыр!

*(«Кояш». 1914. 17 август)*

---

[1] Хисса – өлеш.

[2] Матлубыдыр – теләгедер.

[3] Тәтиммәсенең – кушымтасының. Сүз 1912 елның 25 июнендә кабул ителгән «О призрении нижних воинских чинов и их семейств» дигән закон турында бара. Әлеге закон 1913 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертелгән.

[4] Тәүсыя итәр – киңәш бирер.

## МӨФТИЛЕК МӘСЬӘЛӘСЕ ВӘ АҢАР КАНДИДАТЛАР

*Мөфтилек тирәсендә татар әфкяре гомумиясе[1]. Матбугат берлеге. Оптимистлар вә пессимистлар. Гыйниятулла Капкаев вә «садака» мәсьәләсе. Сафа мәхдүм вә гайреләр.*

Сабикъ[2] мөфти Солтанов[3] вафат иткән көннән соң, мөфтилек мәсьәләсе гаҗәеп дәрәҗәдә татар әфкяре гомумиясен мәшгуль итә башлады. Кайда барма, кем белән очрашма, ике-өч татар бергә тугры килгән һәрбер җирдә мөфтилек мәсьәләсе мөзакәрә ителә:

Кем мөфти булачак? Дөрест әйтергә кирәк, мин әле үз халкымызның шушындый бер көндә мөфтилек мәсьәләсе белән бу кадәр кызу шөгыльләнүен көтә алмыйдыр идем, татар әфкяре гомумиясенең аз бер еллар эчендә шундый бер хәрәкәтчелек (активность) күрсәтә алуын өмид итәргә читенсенә идем. Бик күп милли мәсьәләләремездәге шикелле, бунда да татарда әле әфкяре гомумия эшләнеп җитмәгәнлекнең әсары күренер, монда да милләтнең кул селтәбрәк караганлыгы тагы бер кат заһир булыр төсле иде, ләкин үземезнең гаид шатлыгыма каршы, хәзер мин фикри бер торгынлык урынында, бер хәрәкәтчәнлек, мәсьәләнең әһәмиятен аңлаганлык күрәм:

Казанның бөтен татар даирәсе бер көн шул мәсьәлә тирәсендә фикер йөртә вә шул мәсьәлә тирәсендә сүз сөйли...

Әле ул гынамы, шул фикер йөртүчеләр вә шул сүз сөйләүчеләр һәммәсе ниндидер бер кодрәт кулы белән әсаслары бер үк ноктада җыела торган бер фикер тирәсенә оештырылганнар. Һичбер төрле дим, дәлаләт итү (пропаганда) булганы юк, һичбер төрле тәртипкә салынган гомуми җыелышлар булганы юк, матбугат әле үз тарафыннан чын-чынлап эшкә керешеп, катгый мөгайян[4] булган бер ноктаны алга сөргәне юк – шулай була торып, әфкяре гомумия үз-үзеннән инде бер нокта тирәсенә якынлашып өлгергән.

Урта Русия мөселман матбугат мувәкъкатәсе[5], алдан һичбер төрле мөзакәрә итмичә[6], үз-үзеннән бертөрле ноктаүлар тирәсендә оешты:

Имин, гафиф[7] милләткә иҗаби җәһәтеннән[8] танылган сәвияи мәдәниясе[9] белән югары урын ишгаль итә[10] торган кеше генә мөфти булырга тиеш! – диде.

---

[1] Әфкяре гомумиясе – гомуми фикере.

[2] Сабикъ – элекке, әүвәлге.

[3] Дин эшлеклесе Мөхәммәдьяр Мөхәммәдшәриф улы Солтанов (1836–1915) – 1866–1885 елларда Уфа губернасы Минзәлә һәм Бәләбәй өязләрендә мировой арадашчы, казый. 1886 елдан Оренбург мөселманнары диния нәзарәте мөфтие.

[4] Мөгайян – билгеле, ачык.

[5] Матбугат мувәкъкатәсе – вакытлы матбугаты.

[6] Мөзакәрә итмичә – фикер алышмыйча.

[7] Гафиф – саф, пакь.

[8] Иҗаби җәһәтеннән – уңай яктан.

[9] Сәвияи мәдәниясе – мәдәни тигезлеге.

[10] Урын ишгаль итә – урын тота, били.

Төрле сыйныф халкының нәкыль әфкяре[1] булган мәсләкләре дә беркадәр аерыла торган урта Русия мөселман матбугат мувәкъкатәсе, фәкать хакның шул төрле-төрле сыйныфларның теләкләрен белгәнлектән генә менә шул фикер тирәсендә тотты да оешты.

Мин соңгы көннәрдә Казан имамнарының иң нөфүзлеләреннән[2] берничәсе белән, Казан мөселман зыялыларының шактыйлары белән, сәүдәгәрләреннән берничә кешеләр белән бу тугрыда сөйләшеп уздым. Дөрестерәк тәгъбирә иткәндә, сөйләшеп уздым да түгел, бәлки аларның фикерләрен тыңладым, алар һәммәсе алдан иттифаклашып[3] куйган шикелле:

Имин, гафиф, милләткә иҗаби җәһәтеннән танылган сәвияи мәдәниясе белән югары тора торган кеше генә мөфти булырга тиеш! – диләр вә шул шартларга тугры килүләре уйланган берничә кешеләрнең исемнәрен зикер итәләр. Нинди даирәгә барма, нинди сыйныфка мәнсүб[4] татар белән сөйләшмә, ул исемнәре зикер ителә торган затлар – бер үк дип әйтергә мөмкин кешеләр, бу даирләрнең һәрберсе шул бер үк кандидатлар тирәсенә оеша алырлык күренәләр. Монафикъ миллияне аңлый башлаудан килеп чыккан бу әфкяре гомумиянең тагы шул ягы шаян игътибар ки, һәрбер даирә үзе күрсәтергә теләгән кандидатын хөкүмәт эчендә кабул ителерлек сәяси мәсләкләре белән могтәдил[5] кешеләр арасыннан сайлаганнар ки, моннан аңлашылуына күрә, әфкяре гомумия бу кандидатларын бер нәмаиш[6] буларак тәкъдим итми, бәлки хөкүмәтнең үз тавышына колак салуын өмид иткәнлегеннән тәкъдим итәдер.

Без, табигый, хөкүмәт даирәсендә бу мәсьәләдә татар әфкяре гомумиясенә колак салынып-салынмаячыгын катгый бер сурәттә әйтә алмыймыз. Ләкин дахилия нәзарәте[7] башына кенәз Щербатовның[8] чакырылуы бу тугрыда өмидле бер вакыйга булса кирәк, диеп зан итәмез[9]. Бу тугрыда мин берникадәр зыялыларның фикерләре белән таныштым, аларның күбрәге кенәз Щербатовның дахилия нәзарәте башында булучылыгын хәерле фал итеп каршы алалар. Моннан да башка сабикъ мөселман фракциясенә мөнасиб депутатлардан берсе белән дә мин бу тугрыда фикер алыштым, ул миңа шундый бер вакыйга зикер итте:

[1] Нәкыль әфкяре – сүз ирегe.
[2] Нөфүзлеләреннән – авторитетларыннан.
[3] Иттифаклашып – берләшеп.
[4] Мәнсүб – караган.
[5] Могтәдил – уртача.
[6] Нөмаиш – күренеш.
[7] Дахилия нәзарәте – Эчке эшләр министрлыгы.
[8] Николай Борисович Щербатов (1868–1943) – җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, эчке эшләр министры (июнь – сентябрь, 1915 ел).
[9] Зан итәмез – уйлыйбыз.

Үткән Дума вакытында мөфти Солтановның истигъфа итү[1] хәбәре чыккач, мәзкүр зат Русиядәге гайре[2] милләтләрнең дини эшләрен идарә итүче господин Минкинга[3] мөрәҗәгать итеп, аннан бу тугрыда нинди хәрәкәт көтәргә мөмкин икәнчелеген сорашкан. Хосусый бер мәҗлестә вә хосусый сөйләштә бирелгән бер сөальгә господин Минкин болай диеп җавап биргән:

– «Мин әле ул тугрыда катгый бер сүз әйтә алмыйм, ләкин шулай да уйлыйм, бу тугрыда без мөселман фракциясенең әгъзаларыннан фикерләрен сорашырмыз вә алар күрсәткән кандидатлардан үземез өчен мөнасибрагын[4] тәгъйин итәрмез[5]. Әле мадам ки, Думада мөфти сайлау хакында закон үткәргәнеңез юк. Бу юл бердәнбер тугры юл булыр диеп зан итәм», дигән.

Менә болардан аңлашылуына күрә, хөкүмәтнең бу тугрыда татар әфкяре гомумиясенә игътибар итәчәген тәхмин итәргә мөмкин булачактыр.

Болай диеп уйлаган өчен мине артык оптимист диеп гаепләүчеләр табигый булыр. Мин үземнең оптимизм белән мөбтәля[6] икәнемне бервакытта үз-үземнән дә вә кешедән дә яшермим, фәкать аны гафу иттертү мәҗбүриятендә булынсам, дөньяда шулай тору уңгаерак, дим генә.

Бу мәсьәләдә миңа пессимистлар фикере белән дә танышырга тугры килде. Алар әйтәләр:

– «Татар әфкяре гомумиясенең хөкүмәт даирәләренә фәкать сәлби тәэсире генә булыр. Тотарлар да нинди дә булса Гыйниятулла казый Капкаев[7] яхуд Сафа мәхдүм Баязитовны[8] тәгъйин итәрләр, менә

[1] Истигъфа итү – эштән чыгу.

[2] Гайре – башка.

[3] Россия империясе Эчке эшләр министрлыгының чит диннәр буенча эшләр департаменты җитәкчесе.

[4] Мөнасибрагын – яраклырагын.

[5] Тәгъйин итәрмез – билгеләрбез.

[6] Мөбтәля – дучар.

[7] Гыйниятулла Капкаев (1856–1930) – мөселман дин һәм җәмәгать эшлеклесе, Оренбург мөселманнары диния нәзарәте (1893–1917) һәм БАССР мөселманнары Үзәк диния нәзарәте (1920 еллар) казые. Гыйниятулла Капкаев 1914 елда Санкт-Петербургта ачылган «Сыйрател-мөстәкыйм» («Туры юл») Бөтенроссия мөселманнар берлеген нигезләүчеләрнең берсе булып тора. 1920 елларда БАССР мөселманнары Үзәк диния нәзарәте казые.

[8] Баязитов Мөхәммәдсафа Гатаулла улы (1885–1937) – дин һәм җәмәгать эшлеклесе. 1911 елдан Санкт-Петербургның 2 нче мәхәлләсе имамы, соңрак Санкт-Петербург ахуны һәм Петербург хәрби округы имамы, шул ук вакытта хәрби уку йортларында ислам мөгаллиме, Россия империясе Тышкы эшләр министрлыгы тәрҗемәчесе. «Нур» газетасының мөхәррире һәм нашире. 1914 елда Санкт-Петербургта Бөтенроссия мөселманнарының «Сыйрател-мөстәкыйм» берлеген оештыра һәм аның җитәкчесе була. 1915 елда мөфти итеп итеп билгеләнгәч, 1916 елда Уфада диния нәзарәтенең рәсми басмасы – «Мәгълүмате мәхкәмәи шәргыяи Ырынбургия» журналын чыгаруны яңарта. Февраль революциясеннән соң Сафа Баязитов мөфтилектән төшерелә.

аннан соң мөфти Солтановны сагынып йөрермез, яхуд идарәи руханиямезне телгә алырга җирәнә башлармыз! – диләр.

Ләкин мин һич тә, һич тә вакытка бу ихтималларны башыма китерергә теләмим.

– Ник? – диярсез.

Чөнки... Чөнки бу кешеләр милләткә фәкать сәлби якларыннан танылу белән бергә хөкүмәткә дә боларның чын хезмәт күрсәтә алганлыкларын без беремез дә белмимез. Алыйк Гыйниятулла Капкаевны. Мин бу кешене гомеремдә бер мәртәбә дә күргәнем юк. Ләкин минем аның хакында бик күп нәрсәләр ишеткәнем бар. Зате[1] мулла гаиләсендә туып үскән һичбер кеше, мин уйлыйм, Гыйният казыйга бирелә торган мәшһүр «садака»лар мөнәсәбәте белән аның хакында ишетми кала алмаганнардыр.

Хуш, алыйк Гыйниятулла Капкаев әфәндене.

Бу кешенең образовательный бер цензысы юк, голүм дөньясы соң дәрәҗәдә накыйс[2] (Кышкар хәлфәсе), моның өстенә дә чирек гасыр идарәи руханиядә казый булып торган дәверендә бу кеше идарәи руханияне ислах тугрысында дип әйтим, бәлки идарәи руханиягә тәгъликъле эшләрне бик аз гына бер тәртипкә китерү тугрысында да һичбер вакытта һичбер төрле эш күрсәткәне юк.

Аның чирек гасыр идарәи руханиядә казый булып торуы фәкать сәлби нәтиҗәләр генә бирде. Шулай булгач, ни дип, нәрсә өчен дип, аны мөфти итәргә кирәк. Хөкүмәт даирәләренә бу кешенең хезмәт күрсәткән булуын тагы уйларга юл юк. Чөнки үзенең тугрыдан-тугры вазифасы булган идарәи рухания эшләрен эшләүдә дә бу кеше эшсезлектән башка бернәрсә күрсәтә алмагач, моның нинди даирәдә хезмәт итә алуы мөмкин? Гыйниятулла Капкаевның казыйлык сөрүеннән бер хатирә калса, ул да фәкать аның үзенең Уфада сатып алган пулаты гынадыр. Казыйлык ләвазимендә[3] елга сигез йөз сум вазыйфә[4] алып хезмәт итә торган кешенең зур бер пулатка ия була алуы, табигый, аның бөтенләй булдыксыз кеше түгел икәнен күрсәтә аладыр. Ләкин бу булдыклылык имтихан кылынырга бара торган бичара фәкыйрь шәкертнең унысына, йөзесенә генә түгел, бәлки меңнәренә инде күз яшьләре бәһасенә дә торгандыр. Без – мәдрәсәдә ятып, аннан һәр елны имтиханга бара торган шәкертнең казый әфәндегә «садака» өчен акча хәзерләп киткәнен күреп торган кешеләр. Бу булдыклылыкның бәһасен бик яхшы аңлыймыз. Садака бирү – яхшы эш, фәкыйрь кешегә аны алу да ярый торгандыр. Бәлки, әмма инде «садака» бирү вә «садака» алу – аларның хөкемнәре башкарак. Имтиханга бара торган шәкертләр арасында бер мөтәгариф[5]

[1] Зате – шәхсән үзе.
[2] Накыйс – җитешсез.
[3] Ләвазимендә – хезмәтендә.
[4] Вазыйфә – хезмәт хакы.
[5] Мөтәгариф – билгеле, танылган, мәшһүр.

сүз бар: – «садака» егерме бишлек кәгазь булса, үзең имам-хатыйп мөдәррис буласың, әмма инде садакаң бишлек кенә булса, имам була алуыңа да куан! – диләр.

Бу гынамы соң әле: идарәи рухания тирәсендә мирас низаглары йөрткән һәрбер мулла вә һәрбер мөәззин белә ки, эченә кредитный билет салынган чәйне идарәи рухания тирәсендәге «бәгъзы берәү»ләр яратып эчәләр... Чәе «садака» булган шикелле, эченә салынган билеты да «садака» була.

Вакытында Ризаэддин хәзрәт тә казый булып торды[1]. Ләкин ул Уфадан өстенә бер җонлы тун да ясый алмаган хәлттә китте. Әмма Гыйниятулла әфәнде... ул инде Уфаның чын бае:

– Ходай «бәхет» биргәч, нишлисең соң!

Хәзергә Гыйниятулла хәзрәт тугрысында җитеп торсын, кирәк булса, без аңар тагы бер мәртәбә кайта алырмыз әле, килик Сафа мәхдүм хәзрәтләренә. Мин үземнең оптимистлыгым муҗибенчә[2], аның да мөфти була алуын да хәтеремә китерергә дә теләмим:

– Ник? диярсез.

Чөнки, «Сыйрател-мөстәкыйм» скандалы белә дә исеме былчыранган бу кешенең хәзер һичбер җәһәттән мөфтилек урынына тамгы итәргә хакы юктыр. Ул әллә нинди шөбһәле максудлар өчен, әллә нинди шөбһәле мөәссәсәләргә малны илтеп тыкмакчы булуы белән милләт алдында исемен былчыратса; башлаган эшендә вөҗүдкә чыгара алмаучылыгы белән шул эшне башлаткан даирә арасында да кадерен җуйган булырга тиештер.

Без «Новое время» гәзитәсендә[3] чыккан дача пожары мәсьәләләрен монда хәтергә алып тормыйча гына, бары Сафа мәхдүмнең голүме диния сахибе булмаганы шикелле, гали образовательный цензага да малик түгел икәнен генә хәтергә төшереп китәргә тиеш күрәмез. Кирәк голүме диния әрбабы булу алга сөрелсен, кирәк голүме дөньявия әрбабы булу алга сөрелсен, Сафа мәхдүмнең мөфтилек урынына цензасы юктыр.

Шөбһәле хәрәкәтләр дә, бөтен гомуми мәсьәләләремез дә вак интригачылыкта гаепләнә торган бу кешене мөфти итү рухани идарәне бетерү касды белән генә эшләнергә мөмкиндер. Менә шуңар күрә, бу көндә мин аның мөфти ителүен һич мөмкин күрмим. Моның өстенә Маклаковның[4] дахилия нәзарәте башыннан китүчелеге дә Сафа

---

[1] Ризаэддин Фәхреддин улы Фәхреддинов (1859–1936) – 1891 елдан Уфа шәһәрендә Оренбург мөселманнары Диния нәзарәтендә казый. 1906 елда бертуган Рәмиевләр чакыруын кабул итеп, Оренбург шәһәренә күченеп килә.

[2] Муҗибенчә – сәбәпле.

[3] 1868–1917 елларда Санкт-Петербург (Петроград) шәһәрендә басылган көндәлек сәяси һәм әдәби газета.

[4] Николай Алексеевич Маклаков (1871–1918) – Россия империясе дәүләт эшлеклесе, эчке эшләр министры (1912–1915), Дәүләт советы әгъзасы. 1915 елның 5 июнендә министр вазифасыннан азат ителә, әмма совет әгъзасы булып кала.

мәхдүмнең мөфтилек тамгысын[1] шактый бастырган дип риваять итәләр. Гүя ки, әүвәлдә ул дахилия нәзарәтендә беркадәр хисабтагы «егет» саналса да, соңгы алмашынудан соң аның зәмине[2] бөтенләйгә җуелган[3] имеш.

Менә шушы мөляхәзәләр[4] белән мин пессимистларча, тотарлар да Сафа мәхдүм яхуд Гыйниятулла Капкаевны мөфти итеп куярлар дигән сүә заннарга[5] ышанмыйча, бу тугрыда татар әфкяре гаммәсенә колак салыныр дип уйлауда дәвам итәм.

Моннан соң инде мөфтилеккә әфкяре гомумия тарафыннан күрсәтелә торган затларга бераз тукталырга тугры киләдер.

Бәгъзы бер мәгълүмат җыелып җитүне көтеп, алар тугрысындагы мөляхәзәләрне язуны берничә көнгә кичектереп торырга тугры киләдер.

*(«Кояш». 1915. 26 июнь.)*

*Басмага әзерләде:*

***Хөснетдинова Гөлназ Азат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

*К печати подготовила:*

***Хуснутдинова Гульназ Азатовна,***
*кандидат филологических наук, старший научный сотрудник отдела текстологии Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*kh-gulnaz71@mail.ru*

---

[1] Тамгысын – зур теләген.
[2] Зәмине – җирлеге.
[3] Җуелган – югалган.
[4] Мөляхәзәләр – фикерләр, уйлар.
[5] Сүә заннарга – начар фикерләргә.